# ТАТАРЛАРНЫҢ ДӨНЬЯНЫ МИФОЛОГИК КАБУЛ ИТҮЕ: ТӨП ОБРАЗЛАР ҺӘМ СИМВОЛЛАР

Бер халыкның мифологик күзаллаулар системасын өйрәнү – гуманитар фәннәрнең мөһим юнәлеше, һәм ул борынгы ышануларны реконструкцияләргә генә түгел, аларның хәзерге заман шартларында трансформациясен күзәтергә дә мөмкинлек бирә. Билгеле булганча, һәр халыкның мифологиясе мифологик ышанулар, ритуаллар һәм дөнья төзелеше турында күзаллауларның киң спектрын колачлый, хәтта хәзерге замандагы социаль һәм мәдәни трансформацияләр вакытында да актуальлеген югалтмый. Халык мифологик традициясен үсештә һәм хәзерге чынбарлык контекстында тикшерү – комплекслы фәнара якын килүне таләп итә торган мөһим бурыч.

Л.Х. Дәүләтшинаның «Мир вокруг нас: о современном состоянии мифологической традиции татар» (Казань: ИЯЛИ, 2024. – 120 с.: ил. – (Серия «Обычаи и традиции татарского народа»)) дигән фәнни-популяр монографиясе татар мифологик күзаллауларының традицион аспектларын да, хәзерге заман үзгәрешләрен да аңларга һәм системалаштырырга омтылудан гыйбарәт. Структурасы ягыннан монография төп ике бүлектән тора.

Беренче бүлек – «Как устроен мир: структура Вселенной» («Дөнья ничек төзелгән: Галәм структурасы») – дөньяның килеп чыгышы һәм беренче кешеләр, сакраль география һәм пространство төзелеше турындагы мифологик күзаллауларны өйрәнүгә багышлана. Анда татар мәдәниятендә таралган дөнья яратылу турындагы мифлар, аларның борынгы төрки космогоник модельләр белән бәйләнешләры, шулай ук аларга ислам күзаллауларының йогынтысы анализлана. Татарларның традицион мәдәниятендә символик мәгънәгә ия булган йорт һәм юл образларын да кертеп, сакраль киңлек концепциясенә аерым игътибар бирелә. Автор традицион рәвештә җәлеп ителә торган фольклор жанрларын гына түгел, йолаларны һәм ышануларны да тикшерә, аларның коллектив аңда тотрыклылыгын һәм хәзерге шартларда трансформациясен күрсәтә.

Икенче бүлек – «Кто нас окружает: обитатели двух миров» («Тирә-юнебездә кемнәр: ике дөнья вәкилләре») – халык традициясендә бүгенге көндә дә актуаль булган мифологик персонажлар турындагы ышанулар системасын тикшерүдән гыйбарәт. Автор түбән мифология персонажларының төп категорияләрен аерып чыгара: йорт һәм табигать локусларының ияләре, зыян салучы һәм нейтраль затлар һ. б. Хезмәттә аларның функцияләре, йөз-кыяфәтләре, үзүзен тотышлары өйрәнелә. Автор кайбер персонажларның хәтта глобальләшү шартларында да үз характеристикаларын саклап калуларына, ә икенчеләренең исә борынгы ышану калдыклары рәвешендә генә яшәвенә игътибар итә.

Хезмәтнең төп казанышларыннан берсе – татар мифологиясен өйрәнүгә комплекслы якын килү. Автор мифологик күзаллауларның эволюциясен тарихи перспективада анализлап, аларның вертикаль кисеменә дә, халык традициясендә мифологик персонажларның заманча формаларын өйрәнеп, горизонталь кисемгә дә игътибар бирә. Мондый алым татар мифологик традициясенең, структур бөтенлеген саклаган хәлдә, үзгәрүчән шартларга ничек җайлашуын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Хезмәтнең зур өстенлеге – экспедицияләр вакытында автор тарафыннан җыелган кыр материалларының фәнни әйләнешкә кертелүендә. Халык сөйләкләрен, ышануларын, ырымнарын һәм йолаларның тасвирламаларын анализлап, Л.Х. Дәүләтшина татар халкының мифологик күзаллаулар системасының мәдәни үзтәңгәллекнең әһәмиятле өлеше булып калуын билгеле.

Хезмәтнең уңай ягы – аның дисциплинаара характерда булуында, ул татар мифологиясен киң мәдәни контекстта карарга мөмкинлек бирә. Автор чиктәш фәннәр (фольклор, этнография, дин белеме, культурология) мәгълүматларына, шулай ук, борынгы төрки һәм Урта гасырлар татар мәдәнияте язма истәлекләрен дә кертеп, чыганакларның киң спектрына, этнографик материалларга, шулай ук хәзерге тикшеренүләргә һәм кыр язмаларына таяна.

Тикшеренүнең шулай ук гамәли кыйммәте дә зур: ул татар халкының матди булмаган мәдәни мирасын сакларга ярдәм итә. Бу контекстта хезмәт мифологик күзаллауларны документлаштыруда, аларны системага салу һәм төшенүдә мөһим функция үти. Бу яктан ул тикшеренүчеләр, укытучылар, музей хезмәткәрләре һәм халык мәдәнияте белән кызыксынучылар өчен мөһим чыганак булып тора.

Автор татар мифологик традициясенең төп элементларын тәфсилләп тасвирлый, әмма шул ук вакытта кайбер юнәлешләрне алдагы хезмәтләрдә тирәнрәк яктырту сорала. Шуларның берсе – мифологик контекстта этносара бәйләнешләрне өйрәнү. Татар мифологиясе Идел-Урал буенда яшәгән күрше халыклар белән интенсив бәйләнеш шартларында формалаша һәм яши, бу исә мифологик образларның, сюжет һәм ритуалларның үзара үзләштерелүенә китерә. Бу процессны җентекләбрәк өйрәнеп, мәдәни алмашу механизмнарын яхшырак аңларга, мифологик традицияләрнең кисешү нокталарын ачыкларга һәм татар мифологиясенең күрше этнослар белән үзара йогынты ясавын күрсәтергә мөмкин булыр иде.

Татар мифологиясенең сакраль географиясен анализлау да – перспективалы күренеш. Монографиядә сакраль киңлекнең аерым элементлары (йорт, юл, табигый локуслар) тикшерелә, әмма изге урыннар, ритуаль зоналар һәм аларның символикасы турындагы мифологик күзаллауларны җентекләп өйрәнү аша татарларның традицион мәдәниятендә пространстволы кабул итүне киңрәк аңларга мөмкин булыр иде.

Китап фольклор, этнография, культурология өлкәсендәге белгечләргә, шулай ук татар халкының рухи мирасы белән кызыксынучы киң катлау укучыларга адресланган. Ул татар мифологиясенең традицион аспектларын ачып кына калмый, XXI гасырда аның актуальлеге, глобальләшү шартларында мифологик күзаллауларның трансформацияләнүе һәм аларны саклау юллары турындагы мәсьәләләрне дә көн тәртибенә куя.

Тулаем алганда, «Мир вокруг нас: о современном состоянии мифологической традиции татар» дигән китап – татар мифологиясе һәм аның хәзерге замандагы яшәеше турындагы фәнни күзаллауларны киңәйтә торган тикшеренү. Ул бу өлкәдә моннан соңгы хезмәтләр өчен ныклы нигез хезмәтен үти.

***Ильина Галина Геннадьевна,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Ильина Галина Геннадьевна,***
*кандидат филологических наук, доцент,*
*ведущий научный сотрудник Чувашского государственного института*
*гуманитарных наук*

*galiil69@mail.ru*